**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Ул.Молодежная, д.73,
с. Тубылгы тау,423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ТУБЫЛГЫ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Яшьләр урамы, 73
Тубылгы Тау авылы,423181

тел.: (8-84348) 3-82-58, факс: (8-84348) 3-82-44, Tub.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2018 нче елнын 09 гыйнваре № 2

2018 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге территориясендә наркотикларга каршы чаралар планын раслау турында

Россия Федерациясе Президентының «2020 елга кадәр Россия Федерациясендә наркотикларга каршы дәүләт сәясәте стратегиясен раслау турында» 2010 елның 9 июнендәге 690 номерлы Указы нигезендә, наркомания таралу куркынычын минимальләштерү максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Наркотик чаралар, психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы тору буенча өстәмә чаралар турында» 2007 елның 18 октябрендәге 1374 номерлы Указына таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Тубылгытау авыл җирлеге территориясендә 2018 елга наркотикларга каршы чаралар планын (1 нче кушымта) расларга.
2. Карарны мәгълүмат стендында һәм «Интернет» челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Исмагилов

1 нче кушымта
Тубылгытау авыл җирлеге башлыгының
2018 елның 9 гыйнварындагы
2 нче номерлы карарына

Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге территориясендә 2018 елга наркотикларга каршы чаралар планы.

| № | Эчтәлек | Башкаручылар | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәдәни-массакүләм һәм ял чаралары үткәрү урыннарында наркотик чаралар таралу фактлары турында мәгълүмат җыю, гомумиләштерү һәм анализлау. | Авыл китапханәсе, мәдәният учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) | Ай саен |
| 2. | Җирлек территориясендә наркотикларга каршы чараларны мониторинглау буенча җәмәгатьчелек советы утырышы | Җәмәгатьчелек Советы, полиция вәкиле (килешү буенча) | Ай саен |
| 3. | Кыргый үсентеләрне ачыклау максатыннан Тубылгытау авыл җирлеге хуҗалыклары буенча рейд үткәрү | АҖ башлыгы, полиция вәкиле (килешү буенча) | Җәйге чорда |
| 4. | Авыр тормыш хәлендә калган балаларны ачыклау, балигъ булмаганнар белән рәхимсез мөгамәлә фактларына юл куймау, имин булмаган гаиләләрне ачыклау, балигъ булмаганнарны җинаять кылуга җәлеп итү фактларын ачыклау һәм булдырмау буенча даими рейдлар үткәрү. | АҖ башлыгы, Җәмәгатьчелек Советы, Тубылгытау гомуми белем бирү мәктәбе, балалар бакчасы «Тургай», полиция вәкиле (килешү буенча) | Квартал саен |
| 5. | Яшәү урыны буенча балалар, яшүсмерләр һәм яшьләрнең социаль әһәмиятле эшчәнлеген оештыру. Каникуллар чорында эшкә урнашу. | АҖ башлыгы, Хатын-кызлар советы, Тубылгытау гомуми белем бирү мәктәбе, балалар бакчасы «Тургай» (килешү буенча) | Июнь, июль, август |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Авыл китапханәләрендә наркоманияне профилактикалау буенча чаралар үткәрү (мәгълүмати стендлар, китап укучылар конференцияләре). | Авыл китапханәсе | Квартал саен |
| 7. | Наркомания һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча айлык үткәрү | АЖ башлыгы, Җәмәгатьчелек Советы, Тубылгытау гомуми белем бирү мәктәбе, балалар бакчасы «Тургай», полиция вәкиле (килешү буенча) | Сентябрь |
| 8. | Дискотекаларны, яшьләр массакүләм чараларын кичке вакытта тикшерү буенча рейдлар үткәрү. | АЖ башлыгы, ДНД, Җәмәгатьчелек Советы, полиция вәкиле (килешү буенча) | Ай саен |
| 9. | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән спорт ярышлары уздыру | Тубылгытау гомуми белем бирү мәктәбе, балалар бакчасы «Тургай» | Ай саен |
| 10. | Яшүсмерләргә тәмәке тартуның, алкогольнең, наркоманиянең, ВИЧның кеше сәламәтлегенә зарарлы йогынтысы турында мәгълүмат бирү мониторингы. | Авыл китапханәсе, ФАП | Квартал саен |